Министерство образования и науки Республики Татарстан
Государственное автономное профессиональное образовательное учреждение
«ЕЛАБУЖСКИЙ ПОЛИТЕХНИЧЕСКИЙ КОЛЛЕДЖ»

Рассмотрено
на заседании ЦМК ОУД,
ОГСЭ
____________________
В.Г. Романова
«28» августа 2022г.

Рассмотрено и принято на
Педагогическом совете
Протокол № 1 от 29.08 2022г.

**РАБОЧАЯ ПРОГРАММА**
УЧЕБНОЙ ДИСЦИПЛИНЫ

**ОГСЭ. 05 Татарский язык (деловое общение)**

г. Елабуга, 2022 г.

“Татар теле” предметыннан төзелгән эш программасы түбәндәге дәүләт документларына нигезләнеп ясалды:

1. “Мәгариф турында” Россия Федерациясенең федераль Законы (29.12.2012 №273-ФЗ);
2. “Мәгариф турында” Татарстан Республикасы Законы (гамәлдәге редакциядә);
3. “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы (2004 нче ел, 1нче июль)
4. Гомуми белем бирү оешмаларында рус телендә сөйләшүче балалар өчен “Татар теле” предметыннан үрнәк программа, - Казан китап нәшрияты, - 2016
5. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы “Алабуга политехник көллияте», дәүләт автоном һөнәри бирү учреждениесенең 2018-2019 нче уку елына укыту планы.

15.02.08 Технология машиностроения белгечлеге буенча төзелгән эш программасы Федераль Дәүләт стандартларында күрсәтелгән гомуми белем бирү нәтиҗәләренә куелган таләпләргә нигезләнеп эшләнде.

**Төзүче оешма:** Урта һөнәри белем бирүче «Алабуга политехник көллияте» дәүләт автоном мәгариф учреждениесе

**Төзүчеләр:**
Хайрова Айгөл Равил кызы, 1 нче категорияле укытучы.

Эчтәлек


1. Уку фәненең эш программасы паспорты 4
2. Уку фәненең төзелеше һәм эчтәлеге 8
3. Уку фәнен тормышка ашыру шартлары 15
4. Уку фәнен үзләштерүне тикшерү һәм бәяләү 16

## 1.Уку фәненең эш программасы паспорты

**<u>Татар теле</u>** <u>(эшлекле аралашу)</u>

### 1.1.Программаның куллану өлкәсе

Татар теле (эшлекле аралашу) эш программасы урта һөнәри белем бирүнең техник һәм социаль икътисад юнәлештәге 15.02.08 Технология машиностроения белгечлеге өчен төзелде. Базис укыту планы белән эшләүче урта һөнәри белем бирүче «Алабуга политехник көллияте» дәүләт автоном мәгариф учреждениясендә татар телен укыту программасы 4 бүлектән тора: уку фәненең эш программасының паспорты, уку фәненең төзелеше һәм эчтәлеге, уку фәнен тормышка ашыру шартлары, фәнне үзләштерүнең нәтиҗәсен тикшерү һәм бәяләү.

### 1.2.Фәннең һөнәри белем бирү төзелешендә тоткан урыны:

ОГСЭ. 05 Татар теле (эшлекле аралашу) укыту дисциплинасы гомуми белем биру дисциплиналары блогы эченә керә һәм икенче курста өйрәнелә.

**1.3.Фәннең максаты һәм бурычлары – әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:** белем бирү, танып белү, үстерү.

**Белем бирү:**

– коммуникатив компетенция, татар телендә сөйләшүчеләр белән телдән яки язмача аралашу күнекмәләре булдыру: коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белү;

– адекват рәвештә аралашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, итәгатьле һәм киң күңелле әңгәмәдәш булу.

Укучылар 1-9 нчы сыйныфларда алган белемнәрен тагын да тулыландыралар, киңәйтәләр, гомумиләштерәләр. Урта баскычта өйрәнелгән темалар буенча сөйләшә белүдән тыш, Татарстанның экономик үсеше, фәнни һәм мәдәни үсеше, халыкара элемтәләре, Россиядә һәм дөньяда тоткан урыны, Татарстанның югары уку йортлары, Татарстандагы яшьләр хәрәкәтләре турында иркен аралашуга чыгару максат итеп куела. Шулай ук укучыларны кызыксындырган, борчыган мораль проблемалар буенча да әңгәмәгә керә белүләре күзаллана. Гомумән алганда, 1-9 нчы сыйныф программасын кабатлау, программа темалары буенча сөйләмне камилләштерү күз алдында тотыла.

**Танып белү –**

Татарстан Республикасында яшәүче һәр милләт кешесе үз халкының һәм янәшәдә яшәүче башка милләтләрнең бәйрәмнәрен, традицияләрен аңларга, хөрмәт итәргә, әдәбият-сәнгать вәкилләренең иҗади казанышлары белән үзенең рухи үсешен баета алу мөмкинлегеннән файдаланырга тиеш.

Татар теле өйрәнүне – “башка дөньяга тәрәзә ачу” булырлык һәм шуның аркылы укучының үз яшәешен тулырак аңлавына ярдәм итәрлек итеп оештыру зарур.

**Үстерү –**

Шәхеснең белемле булуы, тәрбиялелек һәм аның фикерләү сәләте үсеше дәрәҗәсеннән дә тора. Югары баскычта балаларның психик үсешен фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив һәм дедуктив фикер йөртүне үстерүгә аеруча игътибар таләп ителә. Үзләштерү процессы уңышлылыгының алшарты булган универсаль уку гамәлләрен куллана белүне камилләштерү – төп максатларның берсе.

**Тәрбия –**

Укучыларның тиешле дәрәҗәдәге тәрбиялелегеннән башка укыту процессын оештыру мөмкин түгел. Шуңа күрә программа эчтәлеген сайлаганда, материалның тәрбияви мөмкинлекләре исәпкә алынды: сөйләм предметы булган әхлакый проблемалар аша укучының үзенә һәм үзенең әйләнә-тирәсендәге кешеләргә карата, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата **шәхси кыйммәтләр формалаштыру максат итеп куелды.**

рү, тәрбия.

**Укытуның планлаштырылган нәтиҗәләре**

Күрсәтелгән максатлар нигезендә татар теле **укытуның планлаштырылган нәтиҗәләре** билгеләнде.

**Укытуның шәхескә кагылышлы нәтиҗәләре:**

– урта гомуми белем бирү мәктәбендә телне гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда татар теленең күп мәдәниятле дөньядагы роле һәм мөһимлеге турында күзаллаулар формалашу;

– татар мәдәниятенең укучылар өчен булган катламы белән танышу, башка мәдәнияткә карата ихтирам хисе уяну, аларда ватанпәрвәрлек хисе уяну;

– әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау; шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге туу.

**Укытуның метапредмет нәтиҗәләре**

Урта белем бирү баскычында татар теле һәм әдәбиятын укыту, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (***танып белү, регулятив, коммуникатив)*** формалаштыруга хезмәт итә.

***Танып белү гамәлләре:***

– төп төшенчәләрне аера белү, гомумиләштерә, аналогия таба, классификация нигезләрен билгели белү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен күрә, логик нәтиҗәләр ясый белү кебек күнекмәләргә ия булу;

– теләсә нинди эшчәнлектә беренче проблеманы аерып ала, аның чишелеш юлларын билгели, иң эффектив чишелеш юлын күрә белү;

– үз эшчәнлегеңә рефлексия ясый, адекват бәя бирә һәм әлеге проблема чишелешен тагын да нәтиҗәлерәк итү өчен үзеңә нәрсә эшләү, нинди юнәлештә камилләшү зарурлыгын ачыклый белү;

– сүзлекләр, башка эзләнү схемаларын актив куллана белү сәләтләре булу;

– уку һәм танып-белү мәсьәләләрен чишү өчен билге, символ, модель, схемаларны үзгәртү һәм куллана белү;

– уку мәсьәләләрен чишү өчен кирәкле информацион ресурсларны ИКТ чаралары аша эзли һәм максатчан куллана белү.

***Регулятив гамәлләр:***

– мөстәкыйль рәвештә максатка ирешү юлларын, шулай ук альтернатив юлларын планлаштыра белү;

– уку һәм танып-белү гамәленең эффектив юлларын сайлап ала белү;

– үзконтроль нигезләрен яхшы белү, уку һәм танып-белү процессында үзбәя, карар кабул итүне аңлы рәвештә сайлый белү;

– үз эшчәнлегеңне планлаштыруга кирәк булган фикерләреңне, хисләреңне белдерү өчен кирәк булган тел чараларын аңлы рәвештә куллана белү.

***Коммуникатив гамәлләр***:

– укучының яшьтәшләре белән бердәм эшчәнлекне оештыра, парларда, индивидуаль һәм төркемдә эшли белү күнекмәсе булу;

– дәлилле итеп үз фикереңне башкаларга җиткерә белү, өлкәннәр һәм яшьтәшләрең белән продуктив уртак гамәл оештыра белү;

– аралашудан соң коммуникатив максатка ирешү турында бәяләмә, йомгак ясау һәм аны дәлилли белү.

**Укытуның предмет нәтиҗәләре**

***Монологик сөйләм:***

– программа кысаларындагы эчтәлек буенча әңгәмәдәшеңнең сөйләмен аңлый, аңа үз карашыңны әйтә, яңа мәгълүматны чагыштыра һәм бәяли белү;

– гади һәм кушма җөмләләрне кулланып, тормышта булган хәлләр, ишеткән яңа мәгълүматлар, үзеңне борчыган проблемалар турында хәбәр итә белү;

– программада тәкъдим ителгән әхлакый проблемалар буенча үз фикереңне белдерә белү.

***Диалогик сөйләм:***

– аралашу процессында төрле репликаларны кулланып, үз фикереңне әңгәмәдәшеңә аңлата белү;

– конкрет проблема буенча әңгәмәдәшең белән бәхәсләшә һәм үз фикереңне дәлилли белү;

– программада тәкъдим ителгән проблема буенча әңгәмәдәшләрең белән иркен аралашуга чыгу.

***Тыңлап аңлау:***

– программада тәкъдим ителгән эчтәлек нигезендә төрле төрдәге тыңлап аңлау күнегүләрен үти белү; сүзләрне, җөмләләрне ишетеп тәрҗемә итә белү; зур булмаган аутентив яки адаптацияләнгән әдәби әсәрләрдән өзекләрне, мәгълүмати характердагы текстларны, вакытлы матбугат язмаларын тыңлап аңлап, эчтәлеге буенча фикер әйтү, аралашуга чыгу;

– әңгәмәдәшеңнең татарча сөйләмен тулысынча аңлау, теле-радио тапшыруларны тыңлап, өлешчә аңлау.

***Уку:***

– уку текстларын татар теленең әйтелеш нормаларын саклап, сәнгатьле һәм аңлап уку;
– укыган текстның эчтәлеген логик бөтеннәргә бүлә белү, план төзи белү

***Язу:***

– укылган әсәр, андагы проблема буенча үз фикереңне язмача җиткерә белү;
– күргән һәм ишеткән турында хикәяләп язу;
– рәсми кәгазьләрне (гариза, автобиография, характеристика, резюме) яза белү;
– әхлакый проблемага карата үз фикерләреңне язу, иҗади биремнәр үтәү.

**Фәнне өйрәнгәнән соң түбәндәге компетенцияләр үзләштерелергә тиеш:**

**ГК 01** Төрле контекстларга карата профессиональ эшчәнлек мәсьәләләрен чишү ысулларын сайлау
**ГК 02** Профессиональ эшчәнлек мәсьәләләрен үтәү өчен кирәк булган информацияне эзләү, анализлау һәм интерпретацияләү
**ГК 03** Үз профессиональ һәм шәхес үсешен планлаштыру һәм реализацияләү
**ГК 04** Коллективта һәм командада эшли белү,коллегалар, җитәкчеләр, клиентлар белән эффектив сөйләшү-аңлашу.
**ГК 05** Социаль һәм мәдәни контекст үзенчәлекләрен исәпкә алып телдән һәм язма коммуникацияне дәүләт телендә гамәлгә ашыру
**ГК 06** Гражданлык-ватанчылык позицияне, традицион гомумкешелек кыйммәтләргә нигезләнгән аңлы тәртипне күрсәтү
**ГК 09** Профессиональ эшчәнлектә информацион технологияләрне куллану.

Освоение содержания учебной дисциплины ОГСЭ.05 Деловой татарский язык обеспечивает достижение следующих **личностных результатов воспитания**:

| | |
|---|---|
| ЛР 2 | Проявляющий активную гражданскую позицию, демонстрирующий |

| | |
|---|---|
| | приверженность принципам честности, порядочности, открытости, экономически активный и участвующий в студенческом и территориальном самоуправлении, в том числе на условиях добровольчества, продуктивно взаимодействующий и участвующий в деятельности общественных организаций. |
| ЛР 5 | Демонстрирующий приверженность к родной культуре, исторической памяти на основе любви к Родине, родному народу, малой родине, принятию традиционных ценностей многонационального народа России. |
| ЛР 7 | Осознающий приоритетную ценность личности человека; уважающий собственную и чужую уникальность в различных ситуациях, во всех формах и видах деятельности. |
| ЛР 8 | Проявляющий и демонстрирующий уважение к представителям различных этнокультурных, социальных, конфессиональных и иных групп. Сопричастный к сохранению, преумножению и трансляции культурных традиций и ценностей многонационального российского государства. |
| ЛР 11 | Проявляющий уважение к эстетическим ценностям, обладающий основами эстетической культуры. |
| ЛР 13 | Готовый соответствовать ожиданиям работодателей: активный, проектно-мыслящий, эффективно взаимодействующий и сотрудничающий с коллективом, осознанно выполняющий профессиональные требования, ответственный, пунктуальный, дисциплинированный, трудолюбивый, критически мыслящий, демонстрирующий профессиональную жизнестойкость. |
| ЛР 19 | Управляющий собственным профессиональным развитием, рефлексивно оценивающий собственный жизненный опыт, критерии личной успешности, признающий ценность непрерывного образования. |

**1.4.Фәнне үзләштерү өчен сәгатьләр саны:**

-максималь уку йөкләнеше: 108 сәгать;

-шул исәптән мәҗбүри аудитор уку йөкләнеше: 72 сәгать;

-укучыларның үзлектән эше: 36 сәгать.

**2. Уку фәненең төзелеше һәм эчтәлеге**

**2.1. Укыту фәненең төрләре һәм саны**

| **Укуның эш төрләре** | Сәгатьләр саны |
|---|---|
| **Укучының максималь уку йөкләнеше** | *108* |
| **Мәҗбүри аудитор уку йөкләнеше** | *72* |
| Шулай ук: | |
| Лаборатор эшләр | - |

| | |
|---|---|
| Практик эшләр | *64* |
| Контроль эшләр | *8* |
| Курс эшләре | - |
| **Укучының үзлегеннән эше (барысы)** | *36* |
| Шулай ук: | |
| Укучынын курс эшләре буенча үзлегеннән эш | *36* |
| **Чыгарылыш нәтиҗәсе дифзачет** | |

**2.2. Уку программасынның эчтәлеге һәм тематик планы** **Татар теле (эшлекле аралашу) (72 сәгать)**

| **Бүлекләр һәм темалар исемлеге** | **Укыту материалының эчтәлеге, практик эш, укучыларның үзлектән эше** | **Үткәрелгән вакыты (сәг.)** | **Үзләштерелəч әк гомуми компетенция** |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| **1 нче бүлек** | **1. Эшлекле аралашу этикасы. Һөнәр сайлау.** | **20 / 9** | |
| Тема 1.1 Телләр белгән-илләр белгән. | Икетеллелек-дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләре. Төрки телләрнең килеп чыгышы һәм формалашуы. Практик эш. | 2 | ГК 03, ГК 02, ГК 04, ГК 05 ГК 06 ГК 09, ГК 10 |
| Тема 1.2 Аралашуның этик нормалары. | Аралашуның этик нормалары. Лекция. Әңгәмә. | 4 | ГК 03, ГК 02, ГК 04, ГК 05 ГК 06 ГК 09, ГК 10 |
| Тема 1.3 Һөнәр сайлау. | Телгә карата күнегүләр. Һөнәр сайлау,татар теленең әһәмияте. Киләчәккә юл сайлау. Теләк һәм мөмкинлекләр. Уку йортлары һәм без сайлаган һөнәрләр. Практик эш. | 2 | ГК01, ГК 02, ГК 04 ГК 05 ГК 09, ГК 10 |
| Тема 1.4 Коллективта уңай психологик климат булдыру. | Коллективта уңай психологик климат булдыру. Әхлаклылык ягыннан коллективка бәя бирү. Әңгәмә. Тест. | 4 | ГК01, ГК 02, ГК 04 ГК 05 ГК 09, ГК 10 |
| Тема 1.5 Конфликт һәм аны чишү. | Конфликт һәм аны чишү. Иҗади дискуссия. Рольле уеннар. | 4 | ГК01, ГК 02, ГК 04 ГК 05 ГК 09, ГК 10 |
| Тема 1.6 Практик эш. | Практик эш. Сорау-җавап формасында эшләү. Докладлар тыңлау. | 2 | ГК01, ГК 02, ГК 04 ГК 05 ГК 09, ГК 10 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Тема 1.7 Контроль эш. | 1 нче бүлек темаларына карата контроль эш. | 2 | ГК01 |
| | **Укучыларның үзлектән эше**<br>**-** “Эшлекле аралашу этикасы” темасына доклад.<br>**-** “Аралашуның этик нормалары” темасына презентация. | 9 | |
| **2 нче бүлек** | **Эшлекле аралашуның төп формалары.** | **24 / 9** | |
| Тема 2.1 Вербаль аралашу. | Тест. Күнегү-күзәтүләр “Ышан миңа”, Вокаль каршылыклар һ.б. | 4 | ГК 02 ГК 05 ГК 06 ГК 09 |
| Тема 2.2 Публика алдында чыгыш ясау сәнгате. | Фонетик күнегүләр. Рольле уеннар. | 4 | ГК 02 ГК 05 ГК 06 ГК 09 |
| Тема 2.3 Вербаль булмаган коммуникация. | Әңгәмә. Рәсемнәр, картиналар өстендә практик эш. “Хисләрне аңла” күнегүе. | 2 | ГК 02 ГК 05 ГК 06 ГК 09 |
| Тема 2.4 Эшлекле аралашуны оештыру сәнгате. | Әңгәмә. Сүзлекләр белән эш. Сөйләмнең төгәллеген, җыйнаклыгын үстерүгә юнәлтелгән күнегүләр. | 2 | ГК 02 ГК 05 ГК 06 ГК 09 |
| Тема 2.5 Эшлекле әңгәмәләр, сөйләшүләр. | Эшлекле әңгәмәләр, сөйләшүләр. Лекция. Рольле уеннар. | 4 | ГК 02 ГК 05 ГК 06 ГК 09 |
| Тема 2.6 Киңәшмәләр, презентацияләр. | Киңәшмәләр, презентацияләр. Уен “Эшлекле киңәшмә”. | 4 | ГК 02 ГК 05 ГК 06 ГК 09 |
| Тема 2.7 Эшлекле аралашу сәнгате – аның нәтиҗәлелеген билгеләүче фактор. | Иҗади дискуссия. Публика алдында сөйләргә әзерләнү һәм чыгыш ясау. | 2 | ГК 02 ГК 05 ГК 06 ГК 09 |
| Тема 2.8 Контроль эш. | 2 нче бүлек темаларына карата контроль эш. | 2 | ГК01 |
| | **Укучыларның үзлектән эше - “**Эшлекле аралашуның төп формалары” темасына доклад.<br>**-** “Публика алдында чыгыш ясау сәнгате” темасына презентация. | 9 | |
| **3 нче бүлек** | **Эшлекле аралашуның нәтиҗәлелеге.** | **18 / 9** | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Тема 3.1 Эффектив аралашуның стратегиясе һәм тактикасы. | Эффектив аралашуның стратегиясе һәм тактикасы. Лекция. Әңгәмә. | 4 | ГК 02 ГК 05 ГК 09 |
| Тема 3.2 Нәтиҗәсез аралашуга китерүче сәбәпләр. | Дискуссия. Тест. Рольле уеннар “Комплимент”, “Таныш булыйк!” | 2 | ГК 02 ГК 05 ГК 09 |
| Тема 3.3 Эшлекле аралашуда нәтиҗәсезлеккә китерүче психологик каршылыкларны җиңү юллары. | Эшлекле аралашуда нәтиҗәсезлеккә китерүче психологик каршылыкларны җиңү юллары. “Эшлекле сөйләшү стильләре” (уен-тест), рольле уен “Конфликтлар”. | 2 | ГК 02 ГК 05 ГК 09 |
| Тема 3.4 Хезмәт урынында этикет. | Лекция. Әңгәмә. Рольле уеннар “Гражданнарны кабул итү”, “Телефон аша эшлекле аралашу”. | 4 | ГК 02 ГК 05 ГК 09 |
| Тема 3.5 Эшлекле аралашуның нәтиҗәлелеген бәяләү. | Иҗади дискуссия. Докладлар тыңлау һәм фикер алышу. | 2 | ГК 02 ГК 05 ГК 09 |
| Тема 3.6 Практик эш. | Эшлекле уен “Компания президентын сайлау”. | 2 | ГК 02 ГК 05 ГК 09 |
| Тема 3.7 Контроль эш. | 3 нче бүлек темаларына карата контроль эш. | 2 | ГК01 |
| | **Укучыларның үзлектән эше - “**Эшлекле аралашуның нәтиҗәлелеге” темасына доклад.<br>**-** “ Эффектив аралашуның стратегиясе һәм тактикасы” темасына презентация. | 9 | |
| **4нче бүлек** | **Эшлекле аралашуда документациянең әһәмияте.** | **8** | |
| Тема 4.1 Эшлекле аралашуның язма формалары буларак эш кәгазьләре. | Эш кәгазьләре һәм алар белән эшләү принциплары турында лекция. | 4 | ГК01, ГК 02 ГК 05 ГК 09 ГК 10 |
| Тема 4.2 Практик эш. | Практикум. Язма документация өстендә эшләү технологиясе. | 2 | ГК01 |
| Тема 4.3 Контроль эш. | 4 нче бүлек темаларына карата контроль эш. | 2 | ГК01 |
| | **Укучыларның үзлектән эше** – “Эшлекле аралашу процессында шәхеснең үсеше” темасына сочинение. | 9 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | **Диференцированный зачет** | 2 | | |
| **Всего 108 часов: 72 аудиторных часов + 36 часов самостоятельной работы** | | | | |

## 3. Уку фәнен тормышка ашыру шартлары

**3.1. Минималь материаль – техник тәэмин ителешкә таләпләр.**
Фән программасы тормышка ашыру кабинет булуны таләп итә: татар теле һәм әдәбияты кабинеты.
*Уку кабинетының җиһазлары:*
язу тактасы, кием шкафы, китап шкафы, өстәл (укучылар өчен), өстәл (укытучылар өчен), урындыклар, интеракив такта.
*Күрсәтмә пособиеләр:*
язучылар портретлары, алфавит, кагыйдәләр стенды, РФ һәм ТР президентлары портретлары.

**3.2.Укытуның информацион тәэмин ителеше**

**Әдәбият**

*Укытучы өчен*
1.Татар теле.10-11 сыйныфлар:татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы/М.З. Зәкиев,Н.В.Максимов.-Казан:татар китап нәшрияты, 2016.-334б.
2.Махмудов А.Г, Гараева Н.Г., Мухаметзянова Л.Ю. Татар әдәбияты= Татарская литература:Учебник – хрестоматия для студентов сред. спец. заведений.-Казань:Магариф,2010.-631с.
3. Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар теле һәм әдәбиятын укыту программасы (рус балалары өчен): 1 – 11 сыйныфлар. – Казан: Мәгариф, 2010. – 79б.
4. Сафиуллина Ф.С., Фәтхуллова К.С. Татар теле: Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәкт.10нчы с-фы өчен д-лек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен)/ Тулыл. 3нче басма.- Казан: Мәгариф,2010.-223б.
5. Сафиуллина Ф.С., Фәтхуллова К.С. Татар теле: Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәкт.11нче с-фы өчен д-лек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен)/ Тулыл. 3нче басма.- Казан: Мәгариф,2010.-255б.

*Студентлар өчен*
1. Галиуллин К.Р.,Раскулова Р.И. Татар теленең орфографик сүзлеге.- Казан: Мәгариф,2010.-399 б.
2. Гарифуллин С.Ф. Татарча-русча-инглизчә сүзлек.- Казан: Татарстан Республикасы”ХӘТЕР” нәшрияты , 2010.-296 б.
3.Насибуллина Р.Н. Татарский язык в таблицах и схемах для русскоязычных учащихся.- Казань: Гыйлем, 2013.- 64стр.
4.Шаяхметова Л.Х. Татарский язык: интенсивный курс .- Казань: Татар.кн. изд.- во,2012.- 223с.

**Интернет – чыганаклар**
1. Татар теле һәм әдәбияты — Википедия ru.wikipedia.org›wiki/Татар теле
2. Казан шәһәре администрациясенең рәсми сайты Week-end в Казани. tatarlar.ru›rubriki/tatresources.html
3. Мин татарча сөйләшәм www.proshkolu.ru
4. Tatar.com.ru : татар теле
5.https://edu.tatar.ru
6. белем.ru

**Өстәмә:**
Таблицалар һәм плакатлар; алышына торган җиһаз һәм күргәзмә әсбаплары; Русско –Татарский словарь, Ф.А.Ганиев, Ф.Ф.Гаффарова , Казань Татарское книжное издательство; Татарча – русча уку – укыту сүзлеге , Ф.А.Ганиев, И.А.Абдуллин, Мәскәү “Рус теле”; “Диктантлар җыентыгы” Ш.Р.Сайкин; “Хәзерге татар әдәби теле” Ф.С.Сафуллина, М.З.Зәкиев; “Башлангыч мәктәптә татар теле укыту методикасы” С.Г.Вагыйзов, Р.Г.Вәлитова; “Татар теленең орфографик – орфоэпик сүзлеге” Х.Сәлимов; “Морфология” М.М. Нигъмәтуллов. “Татар лексикологиясе” Х.Сәлим; “Татар теле” Ч.М.Харисова.

**4.Фәнне үзләштерүнең нәтиҗәсен тикшерү һәм бәяләү**

| **Укыту нәтиҗәсе<br>( белергә, эшләргә тиеш)** | **Уку нәтиҗәләрен тикшерү һәм бәяләү формалары һәм алымнары** |
|---|---|
| 1. Фонетика, лексика тармаклары турында, сузыкларга һәм тартыкларга хас орфоэпик һәм орфографик нормаларны белү, аваз үзгәрешләренә аңлатма бирә белү.<br>2. Татар теленең сүзлек составын белү. Лексикография буенча тулы мәгълүмат бирә белү.<br>3. Сүз төзелеше, сүз ясалышы, кушымчалар турындагы белемнәрне ныгыту.<br>4. Сүз төркемнәре.<br>5. Язу тарихын белү.<br><br>**Сөйләм эшчәнлегенә таләпләр:**<br>1. Орфография, орфоэпия нормаларын үзләштерү, фонетик анализ ясый белү.<br>2. Төрле сүзлекләрдән файдалану күнекмәләрен булдыру.<br>3. Сөйләмдә сүз төркемнәреннән дөрес һәм урынлы файдалану, төгәл итеп анализлау<br>4. Сүзләргә фонетик, морфологик, синтаксик анализ ясый белү күнекмәләрен булдыру, анализ үрнәкләрен камил белү.<br>5. Сүз ясалышын, төзелешен, сүзтезмәләрне тикшерү үрнәкләрен камил белү.<br>6. Орфографик прициплар һәм аларның нормаларын белү.<br>7. Стилистика һәм сөйләм культурасы нормаларын төгәл белү.<br>8. Пунктуация кагыйдәләреннән дөрес файдалану.<br>9. Сөйләм эшчәнлеге буенча тулы мәгълүматлы булу. | Изложение; диктант; тестлар; реферат; сорауларга җавап бирү; күнегүләр эшләү; конспектлар төзү. |